# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге составына керүче Ишки торак пунктында 2022 елга үзара салым кертү турында

№ 3 18 ноябрь 2021 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегенең Ишки торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Ишки торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2022 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

-Ишки торак пунктында Татарстан урамыннан зиратка кадәр юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, ком җәю, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү), Совет урамы, Татарстан урамы арасындагы тыкрыкка вак таш җәю(сатып алу, ташу, ком салу, вак таш җәю, килешү буенча түләү).

-су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау (сууткәргечне алмаштыру, божра һәм янгын краны урнаштыру, материал сатып алу, торбаларны җәю, траншеялар казу, килешү буенча эш өчен түләү)

- инеш аша җәяүлеләр күперен ремонтлау

- Ишки торак пунктында урам светодиодлы лампаларны сатып алу, урнаштыру һәм техник хезмәт күрсәтү.

-Ишки торак пунктында җирле әһәмияттәге юлларны грейдлау һәм кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Ишки авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Р.К.Хафизов